КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 декабрь г.Казань № 1076

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 430 нчы; 2016 ел, 9 апрель, 210 нчы; 2016 ел, 21 ноябрь, 857 нче; 2017 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 797 нче; 2018 ел, 6 апрель, 211 нче; 2018 ел, 31 июль, 623 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның исеме | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасы (алга таба - Программа) |

| | |
|---|---|
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты |
| Программаны төп эшләүчесе | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты |
| Программаның максаты | Россия һәм халыкара туристлык базарларында туризмның үсеп килүче инфраструктурасын, шулай ук мәдәни-тарихи, табигый потенциалын, республиканың вакыйгаи туризм потенциалын һәм кунакчыллык индустриясен үстерүне нәтиҗәле файдалану базасында Татарстан Республикасының туристлык комплексының конкурентлылык сәләтен арттыру |
| Программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасының уңай туристлык имиджын формалаштыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең күләмен һәм төрлелеген арттыру.<br>2. Татарстан Республикасының туристлык-рекреацион комплексын үстерү.<br>3. Конкурентлылыкка сәләтле туристлык продуктын булдыру һәм аны перспективалы туристлык базарларында алга этәрү.<br>4. Гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, республика туристлык продукты сыйфатын, туризм индустриясе объектларында туристларга хезмәт күрсәткәндә кунакчыллык дәрәҗәсен арттыру.<br>5.Туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү |
| Программа-ны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 - 2021 еллар:<br>I этап: 2014 - 2017 еллар;<br>II этап: 2018 - 2021 еллар |
| «Еллар һәм финанслау чыга-наклары буенча бүлеп, Програм-маны финанслау күләмнәре | Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 1 900,5 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 621,3 млн.сум:<br>2014 ел – 20,0 млн.сум;<br>2015 ел – 97,3 млн.сум;<br>2016 ел – 87,1 млн.сум;<br>2017 ел – 231,5 млн.сум;<br>2018 ел – 45,5 млн.сум;<br>2019 ел – 46,1 млн.сум;<br>2020 ел – 46,6 млн.сум;<br>2021 ел – 47,2 млн.сум;<br>федераль бюджет акчасы – 41,8 млн.сум:<br>2017 ел – 41,8 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган |

| | |
|---|---|
| | муниципаль бюджетлар акчасы – 5,1 млн.сум:<br>2014 ел – 3,3 млн.сум;<br>2015 ел – 1,8 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш акча – 1 232,2 млн.сум:<br>2015 ел – 250,0 млн.сум;<br>2016 ел – 779,2 млн.сум;<br>2017 ел – 103,1 млн.сум;<br>2018 ел – 100,0 млн.сум.<br>Программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Программада Татарстан Республикасы териიториясендә туристлык-рекреация һәм автотуристлык кластерларын төзү күздә тотыла.<br>Әлеге чаралар, төзелә торган кластерлар «Россия Федерациясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмын үстерү (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасына кертелгән очракта, тормышка ашырылачак.<br>Программа чараларын финанслау күләмнәре кластерларның проект документларын, Татарстан Республикасы бюджеты акчасының капитал салулар планын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |
| Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү күздә тотыла:<br>Татарстан Республикасына эчке һәм керә торган туристлар агымын арттыру:<br>2014 ел - 1 830,7 мең кеше;<br>2015 ел - 2 050,4 мең кеше;<br>2016 ел  - 2 255,5 мең кеше;<br>2017 ел - 2 481,0 мең кеше;<br>2018 ел - 2 778,8 мең кеше;<br>2019 ел - 3 056,6 мең кеше;<br>2020 ел - 3 362,2 мең кеше;<br>2021 ел – 3 568,2 мең кеше.<br>халыкка күрсәтелгән түләүле турист хезмәтләре күләме:<br>2014 ел - 8 851,0 млн.сум;<br>2015 ел - 9 824,6 млн.сум;<br>2016 ел - 10 708,8 млн.сум;<br>2017 ел - 11 672,6 млн.сум;<br>2018 ел - 12 956,5 млн.сум; |

| | |
|---|---|
| | 2019 ел - 14 122,6 млн.сум;<br>2020 ел - 15 393,7 млн.сум;<br>2021 ел – 16 317,3 млн.сум.<br>туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә әзерлекле белгечләр саны:<br>2014 ел - 400,0 кеше;<br>2015 ел - 425 кеше;<br>2016 ел - 450 кеше;<br>2017 ел - 475 кеше»; |

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның максаты, бурычлары, программа чаралары, Программаны тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр тасвирламасы, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Программаның максаты һәм бурычлары югарыда үткәрелгән дөньякүләм туристлыкны үстерү, шулай ук Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында туристлыкны үстерү торышын һәм тенденцияләрен анализлау нигезендә формалашканнар.

Россия һәм халыкара туристлык базарларында үсеп килүче туристлык инфраструктурасын, шулай ук мәдәни-тарихи, табигый потенциалны, республиканың вакыйгалы туристлык потенциалын һәм кунакчыллык индустриясе потенциалын үстерүне нәтиҗәле файдалану базасында Татарстан Республикасы туристлык комплексының конкурентлылыкка сәләтен күтәрү Программаның максаты булып тора.

Программа максатына ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк:

1. Республикасының уңай туристлык имиджын формалаштыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең күләмен һәм төрлелеген арттыру.

2. Татарстан Республикасының туристлык-рекреацион комплексын үстерү.

3. Конкурентлылыкка сәләтле туристлык продуктын булдыру һәм аны эчке һәм халыкара базарларда алга этәрү.

4. Гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, республика туристлык продукты сыйфатын, туризм индустриясе объектларында туристларга хезмәт күрсәткәндә кунакчыллык дәрәҗәсен арттыру.

5.Туристлык һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү.

Республиканың имин туристлык имиджын формалаштыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең күләмен һәм төрлелеген арттыру Россия Федерациясе территориясендә үткәрелә торган махсуслашкан турист күргәзмәләрендә катнашуны, шулай ук Татарстан Республикасында өстенлекле турист проектларын, программаларын һәм маршрутларын билгеләүгә йөз тоткан республика конкурсларын оештыруны күздә тота.

Татарстан Республикасының туристлык-рекреация комплексын үстерү буенча бурычын хәл итү аерым төбәкләрнең бизнес берләшмәләрен дәүләт-шәхси партнерлыкны формалаштыру процессларына җәлеп итү исәбеннән бер төркем

өстенлекле турист кластерларын булдыру эшләрен үткәрүне күздә тота. Бу чакта үз тирәсендә кече һәм урта бизнесны үстерүне активлаштырып, төбәкне үстерү, төбәкара элемтәләрне үстерү нокталары булачак туристлык һәм туристлык-рекреация кластерларының тәэмин итү инфраструктурасын комплекслы үстерү планлаштырыла. Күрсәтелгән челтәр элементларын аеруча популяр маршрутларда, шулай ук шактый зур туристлык кызыксынуы тудыра торган урыннар: тарихи һәм мәдни үзәкләр, күрсәтү объектлары, туристлар өчен кызыклы булган башка урыннар янында урнаштыру планлаштырыла.

Программаның структура оештыручы функциональ элементлары булып «Казан», «Борынгы Болгар шәһәре», «Свияжск остров-шәһәре», «Алабуга ярлары», «Свияга-Лэнд», «Кама энҗесе», «Кама Аланы штп. түбән мәйданы», «Яңа Тура», «Смарт-Сити Казан» туристлык-рекреация кластеры тора, алар кысаларында эчке һәм керүче туристлар агымнарының интенсив үсешен тәэмин итә торган, шулай ук ярдәмче хезмәт күрсәтүләр һәм икътисадның чиктәш тармакларын үстерүгә мультипликатив эффект күрсәтүче төбәкнең аерым территорияләрендә туристлык инфраструктурасын тизләтеп үстерү өчен шартлар тудырылачак.

Туристлык-рекреация кластерларыннан тыш проектлаштыру һәм автотурист кластерларын булдыру каралган, алар федераль трассалар янында урнашачак.

Күрсәтелгән бурычны хәл итү өчен бюджет акчасын һәм инвесторлар акчасын бергә финанслау мөмкинлеген файдалану күздә тотыла. Бюджет акчасы, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет акчасы «Россия Федерациясендә эчке һәм керүче туристлык (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасын тормышка ашыруның II этабында өстенлекле кластерларның инженер инфраструктурасы объекттларын финанслауга, ә инвесторлар акчасын – туристлык-рекреация билгеләнешендәге объектларны финанслауга кертү планлаштырыла.

Реставрацияләнгән тарихи-мәдәни мирас объектларын әйләнешкә җәлеп итү белән бергә туристлык инфраструктурасын үстерү һәм заманча комплекслар төзү төрле юнәлештәге бер төркем яңа туристлык маршрутларын эшләү өчен шартлар тудыралар. Бу туристларның төрле категорияләренең кулланучылар соравын канәгатьләндерергә, туристлык объектларының бөтен сезонда эшләвен һәм туристлар агымының тотрыклы үсүен тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Конкурентлылыкка сәләтле турист продуктын формалаштыру һәм аны эчке һәм халыкара базарларда алга күчерү мәсьәләләрен хәл итү туристлык-рекреация комплексын үстерү буенча алдагы бурычның логик дәвамы булып тора һәм Татарстан Республикасының туристлык брендын формалаштыруны, танылган брендларның конкурентлылык сәләтен үстерү һәм күтәрүне («Борынгы Болгар шәһәре», «Свияжск утрау-шәһәре», «Алабуга» һәм башкалар), шулай ук республика турпродукты ассортиментын киңәйтү һәм туристлыкның өстенлекле юнәлешләре буенча (этник, мәдәни-аңлату, экологик, балыкчылык, авыл туристлыгы, актив хәрәкәт итү ысуллары белән туристлык, сәламәтләндерү, ял һәм рекреация) яңа брендлар формалаштыруны күздә тота.

Татарстан Республикасының туристлык продуктын дөньякүләм һәм эчке туристлык базарларында алга чыгару өчен Программаны тормышка ашыруның барлык вакытында, беренче чиратта, Татарстан Республикасының туристлык

мөмкинлекләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә булуын шактый арттырырга, заманча IT-сервислар, проектлар һәм туристлык өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне эшләүне һәм файдалануны оештырырга, мәгълүмати пропаганда кампанияләрен тармакландыруны һәм Татарстан Республикасының туристлык имиджын туристлар өчен кызыклы юнәлеш буларак формалаштыруга һәм алга чыгаруга йөз тоткан башка чаралар комплексын үткәрүне тәэмин итәргә кирәк.

Гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, республикасының туристлык продукты сыйфатын күтәрү бурычларын хәл итү һәм туристларга хезмәт күрсәтү өчен туристлык продуктының туристлык потенциалын, сыйфатын һәм конкурентлылыкка сәләтен бәяләү, шулай ук күрсәтелә торган туристлык хезмәтләре сыйфатын мониторинглау, тармакны технологик тәэмин итүне камилләштерү, туристлыкның заманча статистикасын формалаштыру белән бәйле республикасының туристлык базарын тикшерүләр үткәрүгә юнәлдерелгән бер төркем чараларны тормыша ашыру планлаштырыла. Әлеге юнәлеш, югары һәм урта һөнәри белемне, кадрлар квалификациясен күтәрүне һәм яңадан әзерләүне, туристлык продукты сыйфаты белән эш итү өлкәсендә туристлык һәм кунакчыллык өлкәсендә иҗтимагый һөнәри оешмалар белән хезмәттәшлек оештыруны кертеп, туристлык өлкәсендә кадрлар әзерләү системасын үстерүне күздә тота. Моннан тыш әлеге бүлеккә заманча туристлык навигациясе системасын булдыру буенча, шул исәптән туристлык объектларына җибәрү буенча төп трассаларда халыкара туристлык практикасында кабул ителгән коңгырт турист күрсәткечләрен урнаштыру буенча чаралар кертелә.

Әлеге чараларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә эчке һәм халыкара базарларда туристлык базарларында туристлык продуктының конкурентлылыкка сәләтен, күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең сыйфатын күтәрү өчен шартлар тудырылачак.

Туристлык һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча бурычларны хәл итү туристлыкның өстенлекле төрләрен үстерүне, туристлык, туристлык индустриясе һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары белән үзара хезмәттәшлекне, туристлык базарында катнашучылар белән багланышларны, туристлык өлкәсендә проектларны тормышка ашыруда юридик һәм физик затларга дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыруны күздә тота.

Республиканың уңай туристлык имиджын формалаштыру бурычын хәл итү, халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләмен һәм төрлелеген арттыру түбәндәге беренче чираттагы чараларга дәүләт ярдәме күрсәтү белән билгеләнә:

Россиякүләм туристлык күргәзмәләрен үткәрү һәм аларда катнашуны оештыру;

туристлык индустриясен үстерүгә йөз тоткан конкурсларны оештыру һәм үткәрү;

конференцияләр һәм семинарлар үткәрүне оештыру һәм аларда катнашу.

Татарстан Республикасының туристлык-рекреация комплексын үстерү эшләре түбәндәге чаралар кысаларында алып барылачак:

республиканың туристлык инфраструктурасының инвестиция тәкъдимнәре база пакетын һәм үстерү проектларын булдыру;

өстенлекле туристлык-рекреация кластерлары һәм туристлык үзәкләренең («Казан», «Борынгы Болгар шәһәре», «Свияжск остров-шәһәре», «Алабуга ярлары», «Свияга-Лэнд», «Кама энҗесе», «Кама Аланы штп. түбән мәйданы», «Яңа Тура», «Смарт-Сити Казан») тәэмин итү инфраструктурасы объектларын капиталь төзү һәм яңарту;

автотуристлык кластерларын проектлау һәм төзү.

Конкурентлылыкка сәләтле туристлык продуктын формалаштыру чаралары һәм аны эчке һәм халыкара базарларга чыгару түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Татарстан Республикасының туристлык брендын формалаштыру;

республика туристлык брендларын үстерү һәм аларның конкурентлылыкка сәләтлелеген күтәрү (Казан, Алабуга, Чистай шәһәрләре һәм Чистай муниципаль районы, Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы, «Борынгы Болгар шәһәре», «Свияжск утрау шәһәре», «Кыш бабай һәм Кар кызы резиденциясе»);

республика туристлык продуктының ассортиментын киңәйтү, туристлыкның өстенлекле юнәлешләре буенча (этник, мәдәни-аңлату, экологик, балыкчылык, авыл туристлыгы, актив хәрәкәт итү ысуллары белән туристлык, сәламәтләндерү, ял һәм рекреация) яңа брендлар формалаштыру, шулай ук социаль әһәмияттәге проектларга һәм башлангычларга  дәүләт ярдәме күрсәтү, республиканың вакыйгалар календарен формалаштыру.

Татарстан Республикасының туристлык прдуктрын алга чыгару чаралары үз эченә түбәндәгеләрне ала:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының туристлык мөмкинлекләре булуны арттыру, туристлык буенча республика сайтын карап тотуны һәм алга этәрүне, шулай ук конкурентлылыкка сәләтле цифрлы контенты, сервисларны кертеп, һәм мәгълүмат ресурсын тулыландыру;

туристлык мәгълүмат үзәкләре челтәрен үстерү һәм алар эшчәнлеген координацияләү (Call-centre кертеп) һәм аларның эшен тәэмин итү, россия һәм чит ил туристлык мәгълүмат үзәкләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасында туристлык турында реклама-имидж материалларын чыгару һәм тарату;

туристлык имиджын формалаштыруга һәм республиканы туристлык базарларында алга чыгаруга юнәлдерелгән халыкара, россиякүләм, төбәкара, республика чараларын оештыру һәм үткәрү, реклама фильмнары һәм роликлар, цикллы телетапшырулар булдыруны, күчмә презентацияләрдә (roadshow) катнашуны, Россия төбәкләре һәм чит илләр вәкилләре катнашында республикада халыкара очрашулар, башка имидж чаралары оештыруны һәм үткәрүне кертеп (шул исәптән «Бөек Идел» проекты һәм башка төбәкара чаралар, Казан – Свияжск, Казан – Болгар маршрутлары буенча еллык авто- һәм велоузышлар кысаларында һәм башкалар).

Республика туристлык продукты һәм туристларга хезмәт күрсәтү сыйфатын күтәрү чаралары, гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, тбәндәгеләрне үз эченә ала:

туристлык базарын туристлык потенциалын, туристлык продукты сыйфатын һәм конкурентлылыкка сәләтен, шулай ук күрсәтелә торган туристлык продуктлары сыйфатын мониторинглауны өйрәнү һәм бәяләү белән бәйле махсус тикшерүләр үткәрү;

халыкара чараларга туристлык индустриясе кадрлары квалификациясен күтәрүне оештыру;

туристлык һәм кунакчыллык индустриясе өлкәсендә кадрлар әзерләү системасын үстерү;

туристлык индустриясе өлкәсендә коммерциячел булмаган һәм иҗтимагый булмаган оешмаларның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

заманча туристлык статистикасы системасын формалаштыру, мәгълүмат туплау һәм анализлауны оештыру;

заманча туристлык навигациясе системасын булдыру.

Туристлык  һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү мәсьәләсен хәл итү туристлык өлкәсен үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен һәм стратегиясен билгеләүне һәм аларны тормышка ашыруны күздә тота.

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2014 – 2021 еллар. Программа ике этапта тормышка ашырылачак. Беренче этап – 2014 – 2017 еллар, икенче этап – 2018 – 2021 еллар. Төп максат, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук финанслау күләмнәре Программа чаралары кисемендә Программага кушымтада китерелгән.»;

Программаның  V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру 2021 ел ахырына Татарстан Республикасы туристлык базарының конкурентлылыкка сәләтлелеген сизелерлек күтәрергә, шулай ук россия һәм чит  гражданнарының сыйфатлы туристлык хезмәтләренә ихтыяҗын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының туристлык-рекреация комплексы сизелерлек үсеш алачак, туристлык хезмәтләре сыйфаты артачак,  шулай ук дөньякүләм һәм эчке базарларда туристлык продуктын алга чыгару бурычы хәл ителәчәк.

2021 елда Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә эчке һәм керүче туристлык агымнары күләме 3 568,2 мең кеше; туристлык өлкәсендә хезмәтләрне тормышка ашыру күләме – 16 317,3 млн. сум; Программа гамәлдә булуның барлык чорында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсендә әзерләнгән белгечләр саны – 2 100 кеше тәшкил итәчәк.

Программаны тормышка ашыру чорында Татарстан Республикасының туристлык һәм ярдәмче туристлык өлкәсендә эш урыннары 20 мең кешегә кадәр артачак.

Программада каралган чаралар Татарстан Республикасында туристлык үсешендә уңай тенденцияләрне ныгытырга мөмкинлек бирәчәк, бу үз чиратында яңа турислык инфраструктурасын төзүгә һәм гамәлдәге турислык инфраструктурасын яңартуга һәм, нәтиҗә буларак, Татарстан Республикасы территориясендә заманча конкурентлылыкка сәләтле туристлык тармагы төзүгә китерәчәк. Беренчел бәяләүләр буенча, Программаны тормышка ашыру, күрсәтелгән чараларны үтәүне исәпкә алып, аның гамәлдә булу вакыты үткәнгә югары нәтиҗәле туристлык-рекреация инфраструктурасын формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк, киләчәктә Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешен «Туристлык» статьясы буенча үстерүнең алга таба югары динамикасын тәэмин итәчәк.

Программаның күрсәтелгән бурычларын хәл итү республика һәм гомумән алганда Россия Федерациясе икътисадын тотрыклы үстерү өчен мультипликатив эффект бирәчәк, әмма бу бурычлар дәүләтнең һәм муниципаль берәмлекләр кооперациясе һәм шәхси инвесторларның сизелерлек булышлыгы белән проект нигезендә генә тормышка ашырыла ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин